СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**31.07.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 99**

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кушымталарда каралганча кабул итәргә.

2. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән җирлекләрнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән килешүләр төзергә.

3.Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән башкарыла, шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зеленодольск муниципаль районы Советы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз

матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдаланырга хокуклы.

4.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2025 елның 4 августындагы 493 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2026 елның 31 июлендәге
99 номерлы карарына кушымта

**1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге:**

-«Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау һәм карталар белән төзекләндерү;

- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә юл тамгалары салу;

-«Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Стекольный урамыннан Космонавтлар урамына ясалма юл тигезсезлеген урнаштыру;

**2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге**

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау һәм карталар белән төзекләндерү;

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә юл тамгалары салу;

- «Карамалы тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Карамалы тау шәһәр тибындагы поселогында Ленин урамындагы Живоначальная Троица чиркәвенә кадәр баскычтан тротуар салу.

**3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Әйшә авылында Бакча урамы буенча юлны ремонтлау;

- «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау һәм карталар белән төзекләндерү;

**4. Зеленодольск муниципаль районы «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Большие Ключи авылында Сосновый урамындагы юлны ремонтлау.

**5. Зеленодольск муниципаль районы**
**«Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Шырдан авылында авыл мәдәният йортына юл салу.

**6. Зеленодольск муниципаль районы**
**«Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Уразлы авылындагы күпергә юл салу (Подгорная урамына күчү);
- «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Каратмән авылында Клубный урамында 44нче йорттан 40 нчы йортка кадәр юлны ремонтлау.

**7. Зеленодольск муниципаль районы**
**«Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- «Күгеш авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең Айдар авылында мәчет янында парковка ясау.

**8. Зеленодольск муниципаль районы**
**«Новопольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Новопольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Грузинский п. Дачный урамында автомобиль юлын ремонтлау.

**9. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**
**«Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау.

- «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Октябрь п. балалар бакчасына («Форест»т орак комплексы) машина кую һәм керү юлларын төзү.

**10. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**
**«Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау.
- «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Үзәк урамында 7 нче йорт каршысындагы Новониколаевский п. тукталыш павильоны урнаштыру;
- Осиново авылында балалар сәнгать мәктәбенә юл салу һәм парковка ясау.